## ХОКУК

1. Эшмәкәр укыган мәктәбенә микроавтобус бүләк итәргә булды. Бу мисал, барыннан да элек, милек хуҗасының аңа караган мөлкәткә карата нинди мөнәсәбәтен күрсәтә?

**1)** куллану

**2)** ия булу

**3)** идарә итү

**4)** файдалану

2. Дәүләт көче белән саклана торган пунктны күрсәтегез.

**1)** гадәтләр нормасы

**2)** әхлак нормалары

**3)** хокук нормалары

**4)** дини нормалар

3. Россия Федерациясе Президенты

**1)** законнар әзерли һәм кабул итә

**2)** федераль милек белән идарә итүне тормышка ашыра

**3)** федераль бюджетны әзерли

**4)** РФ нең тышкы һәм эчке сәясәтенең төп юнәлешләрен билгели

4. РФ гражданнарының вазыйфаларының берсе -

**1)** дәүләт эшләре белән идарә итүдә катнашу

**2)** мәдәни тормышта катнашу

**3)** закон тарафыннан билгеләнгән салымнар һәм җыюлар түләү

**4)** мал-мөлкәткә ия булу

5. Хокук нормаларын әхлак нормалардан нәрсә аерып тора?

**1)** үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен урнаштыру

**2)** дәүләт тарафыннан үтәргә мәҗбүр итү

**3)** кешеләрнең җәмгыятьтә ирекләрен чикләү

**4)** социаль тормышны җайга салу

6. Үзеңнен намусыңны һәм яхшы атыңны яклауга хокук кайсы төр

хокуклар төркеменә карый?

1) шәхси (гражданлык)
2) сәяси
3) социаль
4) мәдәни

7. Ундүрт яшьлек егет җәйге каникуллар вакытында эшләп алырга уйлаган. Егет, закон нигезендә, нинди вакансиягә урнашырга хокуклы?

1) курьер
2) төнге сменадагы сатучы
3) супермаркетта төяүче
4) тәмәке киоскында сатучы

8. Түбәндәгеләрнең кайсысы башкарма хакимият органнары эшчәнлегенә карый?

1) дәүләт бюджетын әзерләү
2) Президент сайлаулары көнен билгеләү
3) субъектлар арасындагы чикләрнең үзгәрүен раслау
4) законнарны әзерләү һәм кабул итү

9. Саналып кителгәннәрнең кайсысы җинаятькә булып санала?

1) саксызлык нигезендә сәламәтлеккә авыр зыян салу
2) табиб билгеләвеннән башка дару куллану
3) гәҗиттә парламент эшчәнлеген тәнкыйть иткән материал бастырып чыгару
4) коммуналь хезмәтләргә түләүне кичектерү

10. Товарның җитештерүчесе (сатучысы) аның составын күрсәтергә һәм товарны кулланудан мөмкин булган хәтәр факторлар турында кисәтергә тиеш. Әлеге очракта кулланучының нинди хокукы яклана?

1) товар турында тулы мәгълүмат алу
2) зыянны каплау
3) сатып алынган товардан баш тарту
4) кулланучылар белеме

11. Кемдә документның юридик көчкә ия булган күчермәсен эшләргә

һәм расларга була?

1) адвокатта
2) прокурорда
3) җәмәгать судьясында
4) нотариуста

12.РФ нең башкарма хакимият органнары эшчәнлегенә карый торган пунктны күрсәтегез.

1) дәүләт бюджетын әзерләү
2) суд эшчәнлеген тормышка ашыру
3) амнистия игълан итү
4) РФ гражданлыгы мәсьәләләрен хәл итү

13.Башка социаль нормалардан аермалы буларак, хокукый нормалар

1) дәүләтнең көче белән яклана
2) кешеләрнең үз-үзләрен тотуларын җайга сала
3) иҗтимагый фикер көченә таяна
4) күп тапкыр куллануга исәпләнгән

14. РФ нең федератив төзелеше турындагы фикерләр дөресме?
А. РФ составына үзләренең хакимият органнары булган чагыштырмача мөстәкыйль берләшмәләр керә.
Б. РФ субъектлары арасындагы чикләр, аларның уртак килешүләре нигезендә үзгәрергә мөмкин.

1) А гына дөрес
2) Б гына дөрес
3) ике фикер дә дөрес
4) ике фикер дә дөрес түгел

15. Дәүләтнең хокук саклау органнары турындагы фикерләр дөресме?
А. Дәүләт хакимияте органнары тарафыннан законнарның үтәлешен күзәтүне адвокатура гамәлгә ашыра.
Б. Шәхеснең иминлеген тәэмин итү полициянең бурычы булып тора.

1) А гына дөрес
2) Б гына дөрес

3) ике фикер дә дөрес

4) ике фикер дә дөрес түгел

16. Гәҗиттә эре компаниянең эшчәнлеген каралта торган ялган фактлар басылып чыга. Үзенең эшлекле абруен торгызу өчен, компания җитәкчелеге кая мөрәҗәгать итәргә тиеш?

1) полиция бүлегенә

2) судка

3) прокуратурага

4) нотариуска

17. Февраль анда 16 яшьлек Марина эшкә кабул ителә. Июньдә ул, август аенда ял бирүләрен сорап, гариза яза, ләкин предприятие администрациясе Маринаның үтенечен кире кага. Биредә балигъ булмаганнарның хезмәтен билгеләүче кайсы хезмәт законнарының нормасы сакланмаган?

1) Хезмәтнең зарарлы шартларындагы авыр эшләрдә 18 яшьтән кечкенәрәк затларга эшләү тыела.

2) 18 яшьтән кечкенәрәк эшчеләрне төнге һәм эш сәгатеннән тыш вакытта эшләргә тартырга тыела.

3) 18 яшьтән кечкенәрәк эшчеләр үзләренә уңайлы вакытта ел саен түләүле ял алырга хокуклы.

4) Хезмәт килешүе 14 яшьтән өлкәнрәк булганнар белән, ата-ананың берсе һәм медицина белешмәсе булган очракта төзелергә мөмкин.

18. Түбәндәгеләрнең кайсысы РФ Президенты вәкаләтләренә карый?

1) федераль милек белән идарә итү

2) дәүләт бюджетын әзерләү һәм кабул итү

3) РФ субъектлары арасындагы чикләрне билгеләү

4) дәүләт сәясәтенең төп юнәлешләрен билгеләү

19. Гаилә мөнәсәбәтләрен хокукый җайга салу турындагы фикерләр дөресме?
А. Ирле-хатынлыларның һәркайсында шөгыль, һөнәр, яшәү һәм килү-китү урыннарын сайлау иреге була.
Б. Аерылышуны теркәү парларның балигъ булмаган уртак балалары

булган очракта,  суд тәртибендә үткәрелә.

1) А гына дөрес
2) Б гына дөрес
3) ике фикер дә дөрес
4) ике фикер дә дөрес түгел

20. Әхлактан аермалы буларак, нормалар җыелмасы булган хокук

1) илнең өлкән яшьтәге халкына карый
2) дәүләтнең рәсми документларында теркәлә
3) иҗтимагый мөнәсәбәтләрне җайга сала
4) эчке теләк, ният йогынтысы астында башкарыла

21. РФ нең дәүләт хакимияте турындагы фикерләр дөресме?
А. РФ нең Дәүләт Думасы суд хакимиятен тормышка ашыра.
Б. Федераль законнар РФ Президенты тарафыннан кабул ителә.

1) А гына дөрес
2) Б гына дөрес
3) ике фикер дә дөрес
4) ике фикер дә дөрес түгел

22. Норматив хокукый акт

1) иҗтимагый фикер көче белән тәэмин ителә
2) үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен терки
3) компетентлы дәүләт органы тарафыннан кабул ителә
4) һәрвакыт яшәп килгән гадәт һәм традицияләрне чагылдыра

23. Дәрестә укытучы юридик җаваплылыкның төрле төрләре турында сөйләде.
Ике төр юридик җаваплылыкны (административ һәм граждан-хокукый) үзара чагыштырыгыз. Таблицаның беренче баганасына охшаш якларның тәртип номерларын, ә икенче баганага аермалы якларның тәртип номерларын язып куегыз.

1) гаеп эш кылган өчен бирелә
2) хокук бозу өчен кулга алыну

3) зыянны каплау принцибы

4) хокук бозучыны билгеле бер рәхәтләлекләрдән мәхрүм итү

24. РФ Президентының вәкаләтләре турындагы фикерләр дөресме?

А. РФ Президенты дәүләт башлыгы булып тора.

Б. РФ Президенты федераль бюджет әзерли һәм РФ нең Дәүләт Думасына тәкдим итә.

1) А гына дөрес

2) Б гына дөрес

3) ике фикер дә дөрес

4) ике фикер дә дөрес түгел

25. Төрле сәбәпләр аркасында, ике яшьлек кызның әти-әниләре ЗАГС органнарында аның тууын теркәмәгәннәр. Баланың нинди хокукы сакланмаган?

1) көч кулланудан яклану

2) үз ата-анасын белү

3) исем һәм фамилия алу

4) гаиләдә яшәү һәм тәрбияләнү

26. РФ Конституциясе дәүләт мөстәкыйльлеге принцибын урнаштыра. Аның асылы нәрсәдән гыйбарәт?

1) РФ дә Конституциянең өстенлеге, хокук һәм ирекнең гарантиясе тәэмин ителә.

2) Россиянең күпмилләтле халкы дәүләт хакимиятенең бердәнбер чыганагы һәм вәкиле булып тора.

3) Россиядә республика идарә итүе урнаштырылган.

4) РФ дәүләт хакимиятенең һәм федераль законнар чыгару Верховенствосы Россиянең барлык территориясе буенча урнаштырыла.

27. РФ гражданнарының шәхси гражданлык хокукларына нәрсә керә?

1) авырткан очракта социаль тәэмин ителеш

2) ирек һәм шәхси иминлек

**3)** дәүләт эшләре белән идарә итүдә катнашу

**4)** уңайлы әйләнә-тирәлек

28. Төнлә күпфатирлы йортның подъездында шау-шулы яшьләр компаниясе җыелды. Йоклап китә алмаган яшәүчеләр үз районнарының эчке эшләр бүлегенә мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр булдылар. Яшьләр хокукның кайсы өлкәсе нормаларын боздылар?

**1)** административ

**2)** торак

**3)** җинаять

**4)** гражданлык

29. Конституцияне башка норматив хокукый актлардан нәрсә аерып тора?

**1)** югары юридик көчкә ия булу

**2)** дәүләт органнары тарафыннан кабул ителү

**3)** дәүләт көче һәм абруе белән саклану

**4)** һичшиксез үтәлергә тиеш булу

30. Административ хокук бозу күренешенә караган мисалны күрсәтегез.

**1)** җәмәгать транспортында билетсыз бару

**2)** мех салонында тун урлау

**3)** хезмәткәрнең эшкә сонга калып килүе

**4)** башка гражданның мөлкәтен бозу

31. РФ хөкүмәте

**1)** законлылыкны, кешенең хокук һәм ireген тәэмин итү чараларын гамәлгә ашыра

**2)** законнар әзерли һәм кабул итә

**3)** РФ Конституциясенең гаранты булып тора

**4)** РФ гражданлыгын бирү мәсьәләләрен хәл итә

32. Балигъ булмаган Петрны төнге каравылчы итеп эшкә алалар. Биредә балигъ булмаганнарның хезмәтен билгеләүче кайсы хезмәт законнарының нормасы сакланмаган?

**1)** Хезмәтнең зарарлы шартларындагы авыр эшләрдә 18 яшьтән кечкенәрәк затларга эшләү тыела.

**2)** 18 яшьтән кечкенәрәк эшчеләрне 22 сәгатьтән алып 6 сәгатькә кадәр эшкә тартырга тыела.

**3)** 18 яшьтән кечкенәрәк эшчеләр үзләренә уңайлы вакытта ел саен түләүле ял алырга хокуклы.

**4)** Хезмәт килешүе 14 яшьтән өлкәнрәк булганнар белән, ата-ананың берсе һәм медицина белешмәсе булган очракта төзелергә мөмкин.

33. Хокук турындагы фикерләр дөресме?
А. Хокук нормалары бары дәүләт тарафыннан гына билгеләнә, үзгәртелә яки бетерелә.
Б. Хокук барлык җәмгыятькә, дәүләтнең барлык гражданнарына да карый.

**1)** А гына дөрес

**2)** Б гына дөрес

**3)** ике фикер дә дөрес

**4)** ике фикер дә дөрес түгел

34. Хокук нормалары турындагы фикерләр дөресме?
А. Хокук нормалары субъектларга юридик хокук һәм бурычлар хокукы бирә.
Б. Хокук нормалары дәүләт тарафыннан билгеләнә.

**1)** А гына дөрес

**2)** Б гына дөрес

**3)** ике фикер дә дөрес

**4)** ике фикер дә дөрес түгел

35. Михаил ательеда костюм тектерергә биргән. Аның ателье белән мөнәсәбәте кайсы хокук нормалары тарафыннан җайга салына?

**1)** эшмәкәрлек

**2)** хезмәт

**3)** гражданлык

**4)** административ

36. РФ гражданнарының шәхси (гражданлык) хокукына караган пунктны

күрсәтегез.

1) дәүләт эшләре белән идарә итүдә катнашу
2) үз намусыңны һәм яхшы атыңны (исемеңне) яклау
3) социаль тәэмин ителеш
4) уңайлы әйләнә-тирәлек

37. Россия Федерациясенең суд хакимияте вәкаләтләренә нәрсә карый?

1) субъект хокуклары арасында төрле бәхәсләрне хәл итү
2) федераль милек белән идарә итү
3) Россия Федерациясенең Кораллы Көчләренә югары командования билгеләү
4) РФ Президентына сайлаулар көнен билгеләү

38. РФ федератив төзелеше турындагы фикерләр дөресме?
А. РФ субъектлары арасындагы чикләр, аларның уртак килешүләре нигезендә үзгәрергә мөмкин.
Б. Саклау һәм иминлек, тышкы сәясәтне алып бару федераль үзәк карамагында тора.

1) А гына дөрес
2) Б гына дөрес
3) ике фикер дә дөрес
4) ике фикер дә дөрес түгел

39. Иван Петрович эчке эшләр бүлегенә паспортының югалуы турында гариза язды. Хокукның кайсы өлкә нормалары туган хокук мөнәсәбәтен җайга салачак?

1) гражданлык
2) җинаять
3) конституцион
4) административ

40. Дәрестә укытучы хокук бозулар турында сөйләде. Җинаять һәм гаеп эшне үзара чагыштырыгыз. Таблицаның беренче баганасына охшаш якларның тәртип номерларын, ә икенче баганага аермалы якларның тәртип номерларын язып куегыз.

1) нәтиҗәләрнең гадәттән тыш зыяны
2) хокукка каршы эш
3) җинаять җаваплылыгы
4) зыян китерү

41. Административ хокук нәрсәне җайга сала?

1) дәүләтнең финанс эшчәнлеге процессында барлыкка килә торган иҗтимагый мөнәсәбәтләрне
2) хезмәткәрләр һәм эш бирүчеләр арасындагы мөнәсәбәтне
3) башкарма хакимиятне гамәлгә ашыру процессында туган мөнәсәбәтләрне
4) милек һәм милеккә карамаган шәхси мөнәсәбәтләрне

42. Җинаять эше буенча судта дәүләт гаепләвен башкаручыны, гаепләүнүчегә теге яки бу җәза чарасын куллануны таләп итүчене күрсәтегез?

1) нотариус
2) адвокат
3) судья
4) прокурор

43. Һәрбер нигезләмәсе хәреф белән билгеләнгән текстны укып чыгыгыз.
(А) Иҗтимагый эшлеклеләрнең бер төркеме аерылышу процедурасын катлауландыруны күтәреп чыгалар. (Б) Ихтимал, мондый ситуациядә кешеләр гаилә булдыруга бик җаваплы карарлар. (В) Гаиләне саклап калуның мондый хокукый чараларын бары тик хупларга гына кала.
Текстның кайсы нигезләмәләре

1) фактларны чагылдыра
2) фикерләрне белдерә

Тиешле нигезләмәләрнең характерын билгеләүче цифрларны таблицага язып куегыз.

44. РФ Конституциясе мөстәкыйльлек принцибын игълан итә. Бу нәрсәне аңлата?

1) РФ дә идарә итүнең республика формасы

2) дәүләт хакимияте башка дәүләтләр белән мөнәсәбәттә бәйсезлеккә ия

3) РФ дә идеологик күптөрлелек таныла

4) бердәм дәүләт хакимияте өч тармакка бүленә

45. Кеше хокуклары һәм хокук төркеме арасында тәңгәллек урнаштырыгыз: беренче баганада бирелгән һәрбер элементка икенче баганадан туры килә торган элемент сайлап алыгыз.

| **КЕШЕ ХОКУКЛАРЫ** | **ХОКУК ТӨРКЕМЕ** |
|---|---|
| А) һәрбер кеше сәламәтлекне саклау һәм медицина ярдәменә хокуклы | 1) социаль |
| Б) һәркемгә намус иреге гарантияләнә | 2) сәяси |
| В) беркем дә үзенең шәхси тормышына тыкшынуларга дучар булырга тиеш түгел | 3) гражданлык (шәхси) |
| Г) һәркем тыныч җыелышлар һәм ассоциацияләр ирегенә хокуклы | |
| Д) һәркем яшәүгә хокуклы | |

Сайланган цифрларны тиешле хәрефләр астына таблицага язып куегыз.

46. К. гражданины урамны светофорның рөхсәт итмәүче сигналына аркылы чыкты. гражданының бу эше нинди төр җаваплылыкка тартылачак?

1) дисциплинар

2) граждан- хокукый

3) административ

4) җинаять

47. Саналып кителгәннәрнең кайсысы административ хата эш булып тора?

1) законсыз рәвештә иректән мәхрүм итү

2) законсыз рәвештә уллыкка (кызлыкка) алу

3) торак урынының иминлеген бозу

4) юл хәрәкәтләре кагыйдәләрен бозу

48. Командировкадан кайткач, гражданин Л. үзенең фатирының таланганлыгын күрде. Л. гражданына кая мөрәҗәгать итәргә кирәк?

1) арбитраж судына
2) нотариаль конторга
3) җәмәгать судьясына
4) полиция бүлегенә

49. Сергей кибеттә яраксыз товар саттылар дип уйлый. Кулланучы буларак, үз хокукларын яклау өчен, Сергейга нинди чаралар күрергә кирәк?

1) гәҗиткә мәкалә язарга
2) Интернетта тиешле мәгълүмат урнаштырырга
3) нотариуска мөрәҗәгать итәргә
4) судка шикаять белән мөрәҗәгать итәргә

50. Анна бик ашыкты һәм хәрәкәт көчле булган магистральне кызыл төскә аркылы чыкты. Анна нинди хокук бозган?

1) административ
2) дисциплинар
3) гражданлык
4) җинаять

51. Юлия туристлык агентлыгында юллама алды. Аның туристлык агентлыгы белән мөнәсәбәте кайсы төр хокук нормалары белән җайга салына?

1) хезмәт
2) гражданлык
3) административ
4) конституцион

52. Балигъ булган Иван һәм Мария дәүләт теркәве турында ЗАГС бүлегенә гариза тапшырдылар. ЗАГС хезмәткәрләре аларның үтенечләрен кире кагалар. Нинди өстәмә мәгълүмат ЗАГС хезмәткәрләренең бу эшләре хокукка ярашлы булуын аңларга ярдәм итә?

1) Иван һәм Мариянең әтиләре уртак, ләкин әниләре төрле.
2) Мария – католичка, ә Иван – православие динендә.
3) Мария Иваннан 18 яшькә олырак.
4) Иван – тол ир, ә Мария бер тапкыр да кияүдә булмаган.

53. Кешенең социаль-икътисадый хокуклары төркеменә карый торган хокукны күрсәтегез.

1) шәхси тормышның иминлеге
2) закон һәм суд алдында тигезлек
3) сәламәтлек саклау һәм медицина ярдәменә хокук
4) дәүләт хезмәтенә керә алу

55. Россия Федерациясе Президенты функцияләре -

1) законнар әзерләү һәм кабул итү
2) федераль милек белән идарә итү
3) суд карарларын раслау
4) эчке һәм тышкы сәясәт юнәлешләрен билгеләү

56. Һәрбер нигезләмәсе хәреф белән билгеләнгән текстны укып чыгыгыз.

(А) Социологик тикшеренүләр мәгълүматларына караганда, яшьләрнең һәм олырак яшьтәге кешеләрнең хокук һәм шәхес иреге кыйммәтләре турында күзаллаулары шактый аерыла. (Б) Социологлар түбәндәне ачыкладылар: яшьләр,башка яшь категорияләренә караганда, хәтта җәмгыять һәм дәүләт белән ачык конфликтларга ке булса да, үзләренең ирекләрен активрак якларга әзер. (В) Мөгаен, бу - яшьләрнең тормыш тәҗрибәләре җитмәү белән бәйледер.

Текстның кайсы нигезләмәләре

1) фактларны чагылдыра

2) фикерләрне белдерә

Тиешле нигезләмәләрнең характерын билгеләүче хәрефләрне таблицага язып куегыз.

57. Административ хата эшне күрсәтегез.

1) күршегә әҗәтне кайтару
2) автобуста билетсыз бару
3) алимент түләмәү
4) укуга соңга калу

58. РФ нең башкарма хакимият органнары -

1) РФ Хөкүмәте
2) Федерация Советы
3) РФ Дәүләт Думасы
4) РФ Конституцион Суды

59. Милек мирасы мәсьәләләре буенча мәгълүмат алуны, шулай ук мөлкәтне милекка
рәсмиләштерүне кайда эшләргә була?

1) прокуратурада
2) полиция бүлегендә
3) юридик консультациядә
4) иҗтимагый тәртипне саклау пунктында

60. 14 яшьлек егет җәйге каникуллар вакытында эшләп алырга уйлаган. Эш бирүче
закон нигезендә, нинди вакансиягә алырга хокуклы?

1) игъланнар keләйләүче
2) бар официанты
3) супермаркетта йөк төяүче
4) тәмәке киоскында сатучы

61. Укытучы дәрестә юридик җаваплылык турында сөйләде. Гражданлык-хокукый һ
җинаять җаваплылыгын үзара чагыштырыгыз. Таблицаның беренче баганасына охш
якларның тәртип номерларын, ә икенче баганага аермалы якларның тәртип номерлар
язып куегыз.

1) кылган җинаять өчен генә карала
2) дәүләтнең компетентлы органнары тарафыннан гына кулланыла
3) хокук нормалары белән регламент билгеләнә
4) гражданның хөкемгә тартылуын җәлеп итә

62. Сергей Николаевич күп еллар инде бер фатирда яши. Нинди өстәмә мәгълүмат б
фатирның аның милке булуы турында нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә?

1) Бу фатирда элек аның әти-әнисе яшәгән.
2) Теләсә кайсы вакытта ул аны сата ала.

**3)** Ул бу фатирда теркәлгән.

**4)** Бу фатирда аның бөтен гаиләсе яши.

63. Юридик җаваплылык турындагы фикерләр дөресме?
А. Теләсә нинди хокук бозу өчен җинаять җаваплылыгы карала.
Б. Административ җаваплылык һәрвакыт мөлкәттән мәхрүм итүгә китерә.

1) А гына дөрес

2) Б гына дөрес

3) ике фикер дә дөрес

4) ике фикер дә дөрес түгел

64. Әбисе белән оныгы, урманда йөргәндә, Кызыл китапка кертелгән чәчәкләрнең бәйләмен өзеп алалар. Хокукның кайсы өлкәсенә караган нормалар әлеге ситуациян җайга салалар?

**1)** гражданлык хокукы

**2)** административ хокук

**3)** җинаять хокукы

**4)** хезмәт хокукы

65. Владимир ял итү йорты участогы сатып алу өчен банктан кредит ала. Аның бан белән мөнәсәбәте кайсы хокук нормалары белән җайга салына?

**1)** дәүләт

**2)** гаилә

**3)** салым җыю

**4)** гражданлык

66. Гаилә башка шәһәргә күчеп килә. Әти-әнисе 10 яшьлек улларын мәктәпкә урнаштырырга ашыкмыйлар. Нәтиҗәдә, малай ярты ел укымый. Баланың нинди хокукы бозылган?

**1)** үз ата-анасын белү

**2)** үз фикерләрен иркен белдерү

**3)** гаиләдә яшәү һәм тәрбияләү

**4)** белем алу

67. Урта мәктәпнең чыгарылыш сыйныф укучысы ишекне ватып ачып

урлый.  Әлеге ситуация  кайсы хокук мөнәсәбәтләрен күрсәтеп тора?

1) гражданлык
2) җинаять
3) гаилә
4) административ

68. Әнисе белән кызы кредитка автомобиль алалар. Алар  кредит суммасын һәм кредит буенча процентларны  өлешләп түлиләр. Әлеге ситуацияне хокукның кайсы өлкәсе җайга сала?

1) гаилә хокукы
2) административ хокук
3) конституцион хокук
4) гражданлык хокукы

69. Саналып кителгәннәрнең кайсысы  РФ гражданының конституцион бурычы булып тора?

1) салым түләү
2) намус һәм абруй яклау
3) сәяси партияләр эшчәнлегендә катнашу
4) дәүләт органнарына мөрәҗәгать итү

70. Гаилә бер шәһәрдән икенчесенә  күченеп килә.  Ярты ел дәвамында әти-әнисе 12 яшьлек кызларын мәктәпкә урнаштырырга вакыт таба алмыйлар. Баланың нинди хокукы бозылган?

1) тору урынын сайлау
2) үз фикереңне иркен белдерү
3) гаиләдә яшәүә һәм тәрбияләнү
4) белем алу

71. Яшь егетләр балалар мәйданчыгында сыра эчкәннәр. Бу эш нәрсә дип санала?

1) җинаять
2) административ хата эш
3) гражданлык хата эше

4) дисциплинар тәртип бозу

72. Һәрбер нигезләмәсе хәреф белән билгеләнгән текстны укып чыгыгыз.

(А) Яшүсмерләрнең хата эш һәм гамәлләр арасында аермалыклар күрмәүләре бик начар. (Б) Кайвакыт алар “бәхәс белән” дусларының соклануларын уята торган ниндидер “героик эшләр” башкаралар. (В) Хокукка ярашлы булмаган мондый эшләрнең, чын мәгънәсендә, героик гамәлләр була алмавын аңларга кирәктер.

Текстның кайсы нигезләмәләре

| | |
|---|---|
| **1)** | фактларны чагылдыра |
| **2)** | фикерләрне белдерә |

Тиешле нигезләмәләрнең характерын билгеләүче хәрефләрне таблицага язып куегыз.

73. Сергей Иванович яңа телевизор сатып ала. Аның кибет һәм сервис хезмәте белән үзара бәйләнеше, барыннан да элек, түбәндәге хокук нормалары белән җайга салына.

| | | |
|---|---|---|
| | **1)** | административ |
| | **2)** | гражданлык |
| | **3)** | конституцион |
| | **4)** | хезмәт |

74. Әхлак нормаларыннан аермалы буларак, хокук нормаларын үтәү нәрсә белән тәэмин ителә?

| | | |
|---|---|---|
| | **1)** | юристлар фикере белән |
| | **2)** | җәмгыятьнең гадәт һәм традицияләре белән |
| | **3)** | дәүләтнең мәҗбүр итү көче тарафыннан |
| | **4)** | җәмгыять фикере көче белән |

75. Сигез яшьлек Алёшаның әти-әнисе еш кына аңа кычкыралар, тупас сүзләр белән әрлиләр. Бу ситуациядә баланың нинди хокукы бозыла?

**1)** гаиләдә яшәү һәм тәрбияләнү

**2)** кеше абруен хөрмәт итү

**3)** үз фикеңне белдерү

**4)** туганнар белән аралашу

76. Хокукның кайсы өлкәсе милек мөнәсәбәтләрен җайга сала?

| | | |
|---|---|---|
| | **1)** | гражданлык хокукы |
| | **2)** | административ хокук |
| | **3)** | хезмәт хокукы |
| | **4)** | конституцион хокук |

77. Ситуацияләр һәм хокук мөнәсәбәтләре төрләре арасында тәңгәллек урнаштырыгыз: беренче баганада бирелгән һәрбер элементка икенче баганадан туры килә торган элемент сайлап алыгыз.

| **СИТУАЦИЯЛӘР** | | | **ХОКУК МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ ТӨРЛӘРЕ** | |
|---|---|---|---|---|
| **А)** | Министр үз идарә тармагына караган яңа департамент башлыгын билгеләп кую турында боерыкка кул куя. | | **1)** | административ |
| **Б)** | Бабасы оныгына үзенең тәңкәләр коллекциясен бүләк итә. | | **2)** | гражданлык |
| **В)** | Яшь гаилә пары йорт аш-суы кафесы ачты. | | | |
| **Г)** | Фатирда яшәүче үзендә төнге вакытта ремонт эшләре башкарды, дрель белән эшләде һәм күршеләргә йокларга ирек бирмәде. | | | |
| **Д)** | Гаилә башлыгы транспорт агентлыгы белән мебель ташу буенча килешүнамә төзеде. | | | |

Сайланган цифрларны тиешле хәрефләр астына таблицага язып куегыз.

78. Хокук бозу мисаллары һәм хокук өлкәләре арасында тәңгәллек урнаштырыгыз: беренче баганада бирелгән һәрбер элементка икенче баганадан туры килә торган элемент сайлап алыгыз.

| **ХОКУК БОЗУ МИСАЛЛАРЫ** | | **ХОКУК ӨЛКӘЛӘРЕ** | |
|---|---|---|---|
| **А)** | автомобильнең кызыл төскә китүе | **1)** | административ хокук |
| **Б)** | гражданның балалар мәйданчыгында сыра эчүе | **2)** | җинаять хокукы |
| **В)** | гражданның ялган күрсәткечләр | | |

бирүе

**Г)** террористик акт турында күрә торып ялган хәбәр бирү

Сайланган цифрларны тиешле хәрефләр астына таблицага язып куегыз.

79.РФ дәүләт хакимиятенең субъектлары һәм вәкаләтләре арасында тәңгәллек урнаштырыгыз: беренче баганада бирелгән һәрбер элементка икенче баганадан туры килә торган элемент сайлап алыгыз.

| **ВӘКАЛӘТЛӘР** | **ДҮӘЛӘТ ХАКИМИЯТЕ СУБЪЕКТЛАРЫ** |
|---|---|
| **А)** РФ субъектлары арасындагы чикләрнең үзгәрүен раслау | **1)** РФ Хөкүмәте |
| **Б)** амнистиция игълан итү | **2)** Федерация Советы |
| **В)** РФ Президентын сайлаулар көнен билгеләү | 3) Дәүләт Думасы |
| **Г)** федераль бюджет үтәлешен тәэмин итү | |
| **Д)** федераль милек белән идарә итү | |

Сайланган цифрларны тиешле хәрефләр астына таблицага язып куегыз.

80. Кайсы билге хокук нормаларын башка социаль нормалардан аерып тора?

**1)** үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен урнаштыру

**2)** сөйләмә һәм язма формада булу

**3)** яхшылык һәм явызлык турындагы күзаллауларга нигезләнү

**4)** дәүләт тарафыннан кабул ителү

81. Түбәндә саналып newителгәннәрнең кайсысы РФ дә җинаять булып санала?

**1)** подряд килешүе шартларын бозу

**2)** эшкә соңга калу

**3)** шәхси тормышның иминлеге бозылу

**4)** метрополитен белән файдалану кагыйдәләрен бозу

82. Гражданин А. сәбәпсез эшкә килмәде. Бу аны кайсы төр җаваплылыкка тартачак

1) административ

2) дисциплинар

3) җинаять

4) гражданлык-хокукый

83. Гражданин Н. метро вагонында исерек килеш әдәпсез сүзләр әйткән, поездны туктатырга тырышкан. Бу мисал нәрсәгә каршы административ хокук бозу булып тор

1) дәүләт милкенә

2) иҗтимагый тәртипкә

3) идарә итү тәртибенә

4) шәхескә

84. Гражданин Н.  метро вагонында исерек килеш әдәпсез сүзләр әйткән, поездны туктатырга тырышкан. Бу мисал нәрсәгә каршы административ хокук бозу булып тор

1) шәхескә

2) иҗтимагый тәртипкә

3) идарә итү тәртибенә

4) дәүләт хакимияте институтына

85.Башка социаль нормалардан аермалы буларак, хокук нормалары

1) иҗтимагый мөнәсәбәтләрне җайга сала

2) бүләк һәм җәзалар системасын үз эченә ала

3) дәүләт тарафыннан мәҗбүр ителеп тәэмин ителә

4) яхшылык һәм явызлык турындагы күзаллауларга туры килә

86. Хокук бозу булып торган күренешне күрсәтегез.

1) борынгы тәнкәләр хәзинәсен табу

2) судта ялган күрсәтмәләр бирү

3) дуска биргән сүзне бозу

4) паспорт югалту

87. Саналып кителгәннәрнең кайсысы хокук бозу билгесе булып тора?

1) гаепне тану
2) зыян китерү
3) зыян күрүченең гаризасы
4) җинаять эше кузгатылу

88. Саналып кителгәннәрнең кайсысы җинаять булып тора?

1) төзүчеләр бригадасының эшкә килмәве
2) Дәүләт Думасы бинасы янында санкцияләнмәгән митинг оештыру
3) студентларның институт бинасы янында спиртлы эчемлекләр эчүе
4) театр бинасында бомба салыну турында хәбәп итеп, ялган шалтырату

89. Саналып кителгәннәрнең кайсысы хокук бозу булып тора?

1) җылылык челтәре оешмасында ремонт эшләре бару сәбәпле кайнар суны өзү
2) кибетнең ремонтка ябылуы
3) предприятиенең бетерелүе сәбәпле хезмәткәрләрне эштән азат итү
4) сәбәпсез эшкә килмәү

90. Хокук бозу булган очракны күрсәтегез.

1) предприятие администрациясенең күрсәтмәсенә шикаять бирү
2) судта ялган күрсәтмәләр бирү
3) 16 яшь тулгач, килешү нигезендә эш
4) паспорт югалту

91. Гаеп эш – нәрсәгә каршы килә торган тәртип ул?

1) әхлак нормаларына
2) хокук нормаларына
3) сәяси нормаларга
4) этикет нормаларына

92. Юлны тиеш булмаган җирдә аркылы чыгу кайсы хокук нормаларын боза?

1) административ
2) җинаять
3) хезмәт

4) гражданлык

92. Гражданин К. сәбәпсез эшкә килмәде. Бу аны кайсы төр җаваплылыкка тартачак?

1) административ
2) дисциплинар
3) җинаять
4) гражданлык-хокукый

93. Административ хокук мөнәсәбәтләрен башка төр хокук мөнәсәбәтләреннән нәрсә
аерып тора?

1) нормаларның гомуммәҗбүри характеры
2) якларның күлешү иреге
3) якларның иминлек мөстәкыйльлеге
4) якларның тигезсезлеге

94. Хокук бозуны күрсәтегез.

1) җәмәгать урынында спиртлы эчемлекләр эчү
2) милиция хезмәткәрләре тарафыннан тәртип бозучыны тоту
3) сәяси фикерләр буенча, референдумда катнашудан баш тарту
4) эмиграция турында карар кабул итү

95. Хокук бозуны күрсәтегез.

| | | |
|---|---|---|
| | 1) | торак шартнамәсен төзү |
| | 2) | эшсез буларак, хезмәт биржасында теркәлү |
| | 3) | эшкә чыкмау |
| | 4) | кредитка фатир сату |

96. Гражданлык хокук бозуына караган пунктны күрсәтегез.

| | | |
|---|---|---|
| | 1) | янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен бозу |
| | 2) | студентның сәбәпсез дәресләр калдыруы |
| | 3) | авторлык хокукларын бозу |
| | 4) | машина йөртүченең светофорның рөхсәт итмәүче сигналына китүе |

97.Җәмәгать бинасында янгынга каршы сигнализация булмау үзе артыннан кайсы җаваплылыкны тартачак?

| | | |
|---|---|---|
| | **1)** | административ |
| | **2)** | дисциплинар |
| | **3)** | җинаять |
| | **4)** | гражданлык |

98. Саналып кителгән ситуацияләрнең кайсысы хокук бозу күренешенә карый?

| | | |
|---|---|---|
| | **1)** | васыять шартлары белән риза булмаган варислар судка мөрәҗәгать иттеләр |
| | **2)** | кайбер торак пунктларында ураган аркасында электроэнергия бирү туктатылды |
| | **3)** | автоһәвәскәр, куркынычсызлык каешын куймыйча, трассага чыкты |
| | **4)** | укучы контроль эшкә куелган “икеле” белән көндәлеген югалтты |

99. Музейдан картина урлау үз артыннан кайсы җаваплылыкны тарта?

| | | |
|---|---|---|
| | **1)** | административ |
| | **2)** | дисциплинар |
| | **3)** | җинаять |
| | **4)** | гражданлык |

100. Йортта яшәүчеләр урамда үзенең этен борынчыксыз йөрткән гражданин М. өстеннән полиция бүлегенә шикаять белән мөрәҗәгать иттеләр. М. гражданинының әлеге эше кайсы төр җаваплылыкны тартачак?

| | | |
|---|---|---|
| | **1)** | гражданлык-хокукый |
| | **2)** | дисциплинар |
| | **3)** | җинаять |
| | **4)** | административ |

101. Административ хокук бозуына караган пунктны күрсәтегез.

| | | |
|---|---|---|
| | **1)** | шаһитнең белә торып хаталы күрсәткечләр бирүе |
| | **2)** | гражданның милкен бозу |
| | **3)** | сәбәпсез эшкә чыкмау |
| | **4)** | кагыйдәләрдә күрсәтелгән күләм нормаларыннан артып киткән |

| | | |
|---|---|---|
| | | предметларны шәһәр транспортында алып бару |

102. Россия территориясендә югары юридик көчкә ия булган пунктны күрсәтегез.

| | | |
|---|---|---|
| | **1)** | РФ федераль законнары |
| | **2)** | РФ Конституциясе |
| | **3)** | РФ Президенты боерыгы (указы) |
| | **4)** | РФ Хөкүмәте постановлениесе |

103. Саналып кителгәннәрнең кайсысы кешенең табигый хокукларына карый?

| | | |
|---|---|---|
| | **1)** | хәрәкәт итү иреге |
| | **2)** | сайлау һәм сайлану иреге |
| | **3)** | дәүләт эшләрендә катнашу хокукы |
| | **4)** | дәүләт эшенә кабул ителү хокукы |

104. Россия Федерациясендә башкарма хакимиятне гамәлгә ашыра:

| | | |
|---|---|---|
| | **1)** | Генераль Прокуратура |
| | **2)** | РФ Хөкүмәте |
| | **3)** | РФ Федераль Җыелышы (Собрание) |
| | **4)** | РФ Президенты |

105. Кешенең һәм гражданның сәяси хокук төркеменә нәрсә карый?

| | | |
|---|---|---|
| | **1)** | яшәү хокукы |
| | **2)** | шәхси һәм гаилә серенә хокук |
| | **3)** | ял итүгә хокук |
| | **4)** | дәүләт белән идарә итү хокукы |

106. Ата-анасы аерылышканда, суд ничә яше тулган баланың фикерен исәпкә ала?

| | | |
|---|---|---|
| | **1)** | 6 яшь |
| | **2)** | 10 яшь |
| | **3)** | 14 яшь |
| | **4)** | 16 яшь |

107. Ф онституциясе нигезендә дәүләт башлыгы булып нәрсә (яки кем) тора ?

1) РФ Хөкүмәтенең Рәисе
2) РФ Президенты
3) РФ оборона (саклау) Министры
4) РФ Дәүләт Думасы Рәисе

108. РФ дә югары юридик көчкә ия:

1) РФ Президенты боерыгы
2) федераль закон
3) РФ Конституциясе
4) РФ хөкүмәте постановлениесе

109. РФ Хөкүмәте

| | | |
|---|---|---|
| | 1) | законнар әзерли һәм кабул итә |
| | 2) | федераль милек белән идарә итә |
| | 3) | суд карарларын раслый |
| | 4) | гражданлык бирү мәсьәләләрен хәл итә |

110. Әгъзалары алыкка профессиональ юридик ярдәм күрсәтә торган оешма судта гражданнарның мәнфәгатьләрен кайгырта, бу –

1) прокуратура
2) юстициия министлыгы
3) адвокатура
4) нотариат

111. Гражданин К. үзенең улына автомобиль бүләк итәргә уйлады. Тиешле документларны рәсмиләштерү өчен ул кая мөрәҗәгать итәргә тиеш?

1) прокурорга
2) нотариуска
3) судка
4) адвокатка

112. Гражданин тәрәзәдән очраклы рәвештә яшүсмерләрнең кемнеңдер машинасын урларга тырышканнарын күреп алды. Гражданинга, беренче очракта, нәрсә эшләргә кирәк?

1) яшүсмерләне судка тартырга

2) яшүсмерләрне кулга алырга

3) полиция бүлегенә мөрәҗәгать итәргә

4) машина хуҗасын табарга

113. РФ Конституциясе нигезендә, кешенең һәм гражданинның хокукларын һәм иреген саклау нәрсәнең (кемнең) бурычы?

1) судның

2) массакүләм мәгълүмат чараларының

3) депутатларның

4) нотариатның

114. Китерелгән чракларның кайсында адвокат ярдәме кирәк булырга мөмкин?

1) Гражданка Е. үзен законсыз рәвештә эштән чыгардылар дип саный.

2) Гражданка М. паспортын югалтты һәм шуның белән бәйле рәвешле аңа полициягә гариза язарга кирәк.

3) Гражданин А. үзенең улы исеменә автомобильгә ышаныч язуы рәсмиләштерергә уйлады.

4) Гражданин П. җәмәгать транспортында билетсыз йөргән өчен административ җаваплылыкка тартылды.

115. Кеше хокукларының төрле классификациясе бар. Кешенең гражданлык (шәхси) хокукларына караган хокукны күрсәтегез.

1) дәүләт эшләре белән идарә итүдә катнашу

2) гадәти шартларда хезмәт

3) торакның иминлеге

4) сәламәтлекне саклау һәм медицина ярдәменә хокук

116. Әбисе оныгына үзенең пенсиясен алырга ышаныч язуы язды. Ышаныч язуы дөрес булсын өчен, әбинең имзасын кем расларга тиеш?

1) прокурор

2) судья

3) нотариус

4) адвокат

117. Кешенең гражданлык (шәхси) хокукларына караган хокукны күрсәтегез.

1) торакка

2) үз намусын һәм яхшы атын яклауга

3) яшь буенча социаль тәэмин ителешкә

4) белемгә

118. Марк үзенең яхшы танышына, тапшыру актында әҗәтнең вакытын, суммасын күрсәтеп һәм нотариаль раслап, зур суммалы акча биреп торды. Күрсәтелгән вакытта аңа әҗәт кайтарылмаган. Әҗәтне кире кайтарттыру өчен, Маркка кая мөрәҗәгать итәргә кирәк?

1) полиция бүлегенә

2) судка

3) нотариуска

4) салым инспекциясенә

119. 14 яшьтән алып 18 яшькә кадәрле булган балигъ булмаган затларның үз милкуләре белән файдалана алу хокукы кайсы төр хокук нормалары белән җайга салына?

1) гаилә

2) гражданлык

3) хезмәт

4) конституцион

120. Гражданин В., икенче чираттагы варис буларак, вафат булган абыйсының мирасына дәгъва итә. Суд тикшерүе өчен кайсы төр хокукның нормалары нигез булып торыр?

1) административ

2) гражданлык

3) конституцион

4) финанс

121. Эшмәкәр П. Кара диңгез буенда дүрт вилласы бар. Берсен ул сатып алган, ә өчесе әтисеннән мирас итеп күчкән. Әлеге ситуация хосусый милек иясенең нинди хокукын күрсәтә?

1) хуҗа булу

2) идарә итү

3) файдалану

4) мирас итеп бирү

122. Гражданка Иванова үзенең ятим калган туганнан туган энесе өстеннән опека рәсмиләштерде. Әлеге ситуация хокук мөнәсәбәтләренең кайсы хокук нормалары белән җайга салына?

1) административ

2) гаилә

3) гражданлык-процессуаль

4) хезмәт

123. Иван Петрович тузан суырткычы сатып ала. Аның кибет һәм сервис хезмәте белән үзара бәйләнеше, барыннан да элек, кайсы хокук нормалары белән җайга салына?

1) административ

2) гражданлык

3) конституцион

4) хезмәт

124. Ата-ананың хокук һәм бурычлары турындагы фикерләр дөресме?

А. Баладан еракта яшәүче ата-ана аның белән аралашырга хокуклы.

Б. Балалар турында кайгырту, аларны тәрбияләү – ата-ананың тигез хокукы һәм бурычы.

1) А гына дөрес

2) Б гына дөрес

3) ике фикер дә дөрес

4) ике фикер дә дөрес түгел

125. РФ Президентының вәкаләтләре турындагы фикерләр дөресме?

А. РФ Конституциясе нигезендә, РФ Президенты РФ Хөкүмәтенең отставкасы турында карар кабул итә.

Б. РФ Президенты дәүләт бюджетын әзерли һәм кабул итә.

1) А гына дөрес

2) Б гына дөрес

3) ике фикер дә дөрес

4) ике фикер дә дөрес түгел

126. РФ дәүләт хакимияте урындагы фикерләр дөресме?
А. РФ Хөкүмәте бюджет әзерләү белән шөгыльләнә.
Б. Совет Федерациясе РФ Президентына сайлауларны билгели.

1) А гына дөрес
2) Б гына дөрес
3) ике фикер дә дөрес
4) ике фикер дә дөрес түгел

127. Кеше хокуклары турындагы фикерләр дөресме?
А. Кеше хокуклары бүленмәс: һәрбер кеше барлык хокуклар җыелмасына ия.
Б. Кешенең социаль-икътисадый хокукларына вакытында салым түләү дә кертелә.

1) А гына дөрес
2) Б гына дөрес
3) ике фикер дә дөрес
4) ике фикер дә дөрес түгел

128. РФ Президенты турындагы фикерләр дөресме?
А. РФ Президенты РФ Хөкүмәтенең отставкасы турында карар кабул итә.
Б. РФ Президенты РФ хәрби доктринасын раслый.

1) А гына дөрес
2) Б гына дөрес
3) ике фикер дә дөрес
4) ике фикер дә дөрес түгел

129. Хокук һәм әхлак берлеге турындагы фикерләр дөресме?
А. Хокук һәм әхлак социаль нормаларның бер төрчәсен белдерә.
Б. Хокук һәм әхлак субъектларның тиешле һәм мөмкин булган гамәлләренең чикләрен билгели, шәхси һәм иҗтимагый мәнфәгатьләрнең гармониясен җайга салу чарасы булып хезмәт итә.

1) А гына дөрес
2) Б гына дөрес
3) ике фикер дә дөрес

4) ике фикер дә дөрес түгел

129. Гадел хөкем турындагы фикерләр дөресме?
А. Россия Федерациясендә гаепләнүче үзенең гаепсезлеген дәлилләргә мәҗбүр түгел.
Б. Россия Федерациясендә гадел хөкем бары тик суд белән генә гамәлгә ашырыла.

1) А гына дөрес
2) Б гына дөрес
3) ике фикер дә дөрес
4) ике фикер дә дөрес түгел

130. Гражданин А. талау һөҗүменә дучар булды. Аның автомобилен яулап алган җинаятьчеләр акчаларын, кыйммәтле әйберләрен тартып алып, үзен машинадан чыгарып ташлыйлар. Гражданин А.-га, беренче чиратта, кая мөрәҗәгать итәргә кирәк?

1) полиция бүлегенә
2) прокуратурага
3) адвокатка
4) җәмәгать судьясына

131. Ирле-хатынлы Нора һәм Вадим никах килешүе төзергә уйлыйлар. Аларга кая мөрәҗәгать итәргә кирәк?

1) адвокатка
2) полиция бүлегенә
3) нотариуска
4) җәмәгать судьясына

132. Балигъ булмаганнарның эшкә урнашу үзенчәлекләре турындагы фикерләр дөресме?
А. 18 яше тулмаган затлар эшкә сынауларсыз кабул ителәләр.
Б. Балигъ булмаган затлар барларда, ресторannarda эшли ала.

1) А гына дөрес
2) Б гына дөрес
3) ике фикер дә дөрес

4) ике фикер дә дөрес түгел

133. Балигъ булмаганнарның эшкә урнашу үзенчәлекләре турындагы фикерләр дөресме?

А. Балигъ булмаган зат белән хезмәт килешүнамәсе төзегәндә, ике якның да килешүе буенча, сынау вакыты билгеләнергә мөмкин.

Б. Балигъ булмаган хезмәткәрләргә 40 сәгатьлек эш атнасы билгеләнә.

1) А гына дөрес

2) Б гына дөрес

3) ике фикер дә дөрес

4) ике фикер дә дөрес түгел

134. РФ дә кулланучыларның хокуклары турындагы фикерләр дөресме?

А. Әгәр дә товар куллануда булмыйча һәм аның төрелгән кабы сакланса, кулланучы 14 көн эчендә теләсә кайсы товарны алыштырырга яки аны сатып алудан баш тартырга хокуклы.

Б. Кулланучыга рус телендә фирма-җитештерүче яки сатучы тарафыннан, товар турында, аның дөрес сайлау мөмкинлеген тәэмин итә торган, кирәкле һәм дөрес булган мәгълүмат тәкъдим ителергә тиеш.

1) А гына дөрес

2) Б гына дөрес

3) ике фикер дә дөрес

4) ике фикер дә дөрес түгел

135.Гражданнарның хокукларын саклау турындагы фикерләр дөресме?

А.Законсыз рәвештә эштән куылган очракта хезмәткәр судка мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Б. Прокуратура гражданнарга аларның хокукларын яклап калырга ярдәм итә.

1) А гына дөрес

2) Б гына дөрес

3) ике фикер дә дөрес

4) ике фикер дә дөрес түгел

136.Халыкара гуманитар хокук турындагы фикерләр дөресме?

А. Халыкара гуманитар хокук теләсә кайсы корал куллануга каршы.

Б. Халыкара гуманитар хокукның максаты булып, социаль конфликт формасы буларак, сугышларны тулысынча тыю тора.

1) А гына дөрес

2) Б гына дөрес

3) ике фикер дә дөрес

4) ике фикер дә дөрес түгел

137. Ата-ананың хокук һәм бурычлары турындагы фикерләр дөресме?
А. Баладанеракта яшәүче ата-ана аның белән аралашырга хокуклы.
Б. Ата-ананың бурычы – үзенең балаларын тәрбияләү.

1) А гына дөрес

2) Б гына дөрес

3) ике фикер дә дөрес

4) ике фикер дә дөрес түгел

138. Административ җәза билгеләү турындагы фикерләр дөресме?
Административ җәза билгеләнгәндә исәпкә алына:
А. кылган хокук бозуның характеры
Б. бозучының белем дәрәҗәсе һәм профессиясе

1) А гына дөрес

2) Б гына дөрес

3) ике фикер дә дөрес

4) ике фикер дә дөрес түгел

139. Кешенең һәм гражданинның хокук һәм ирек саклау гарантияләре турындагы фикерләр дөресме?
РФ Конституциясе һәм законнар гарантия бирәләр:
А. һәркемнең суд яклавы хокукына
Б. һәркемнең үз хокукларын, ирегең һәм законга сыешлы мәнфәгатьләрен закон тарафыннан тыелмый торган барлык ысуллар белән яклау хокукына

1) А гына дөрес

2) Б гына дөрес

3) ике фикер дә дөрес

4) ике фикер дә дөрес түгел

140. РФ дәүләт хакимияте органнары турындагы фикерләр дөресме?
А. РФ дә башкарма хакимиятне Дәүләт Думасы гамәлгә ашыра.

Б. Федераль законнар РФ Хакимияте тарафыннан кабул ителә.

1) А гына дөрес

2) Б гына дөрес

3) ике фикер дә дөрес

4) ике фикер дә дөрес түгел

141. Укытучы дәрестә “РФ дә дәүләт хакимияте органнары” темасын аңлатты. РФ нең башкарма һәм законнар чыгаручы хакимиятен үзара чагыштырыгыз. Таблицаның беренче баганасына охшаш якларның тәртип номерларын, ә икенче баганага аермалы якларның тәртип номерларын язып куегыз.

1) хакимиятнең мөстәкыйль бер тармагы булып тора

2) закон чыгару инициативасына ия

3) хакимиятнең вәкаләтле органы булып тора

4) РФ Хөкүмәте Рәисе җитәкчелендә эшли

142. Укытучы җәмгыять белеме дәресендә үзенең укучыларына гражданнарның хокукларын саклау системасы турында сөйләде. Адвокатура һәм прокуратураны чагыштырыгыз. Таблицаның беренче баганасына охшаш якларның тәртип номерларын, ә икенче баганага аермалы якларның тәртип номерларын язып куегыз.

1) гражданнарның мәнфәгатьләрен яклый

2) юридик консультацияләр алып бара

3) дәүләт органы булып тора

4) җинаять хөкем эшләрен башкаруда катнаша

143. Викторга – 12 яшь, Антонга – 15 яшь. 12 һәм 15 яшьлек яшүсмерләрнең эшкә яраклылык күләмен (хокук нормаларын) чагыштырыгыз. Таблицаның беренче баганасына охшаш якларның тәртип номерларын, ә икенче баганага аермалы якларның тәртип номерларын язып куегыз.

1) вак көнкүреш килешү эшен башкару

2) үзенең эш хакы, стипендия һәм башка керемнәр белән идарә итүе

3) нотариаль таныклыклар таләп ителми торган, түләүсез файда алуга юнәлдерелгән килешүләр башкару

4) кредит оешмаларына кертем ясау һәм алар белән идарә итү

144. Югары сыйныф укучысы, юл йөрү кагыйдәләрен бозып, юлны светофорның

кызыл төсенә йөгереп чыкты. Аның эше нәрсә дип карала?

**1)** җинаять

**2)** административ хата эш

**3)** амораль гамәл

**4)** дисциплинар хата эш

145. Эш-хәрәкәтләрнең китерелгән исемлегендә административ хата эш булып саналганын күрсәтегез.

**1)** җәмәгать урынында әшәке сүзләр әйтү

**2)** системалы рәвештә мәктәп шөгыльләрен сәбәпсез калдыру

**3)** мәктәп дискотекасында наркотик матдәләр тарату

**4)** мәктәп директорының боерыкларын үтәүдән баш тарту

146. Түбәндәгеләрнең кайсысы баланың аерым бер хокукы булып тора?

**1)** фикер, намус һәм дин хокукы

**2)** сәламәтлекне саклау хокукы

**3)** шәхси тормышка тыкшынудан саклау хокукы

**4)** ата-анасын югалткан очракта, опекага ия булу хокукы

147. Гражданка К. чит телләр өйрәтү курсында уку өчен акча түләде, ләкин кире уйлап, үзенең акчасын кайтарырга уйлады. Әмма курслар администрациясе аңа түләнгән акчасын кайтарудан баш тартты. Эшнең судта тикшерелүе өчен кайсы хокук нормалары нигез булып торыр?

**1)** административ

**2)** хезмәт

**3)** гражданлык

**4)** конституцион

148. Җир кишәрлеген киптерү максатыннан, гражданин З. үзенең һәм күршесенең җире уртасыннан канау үткәрергә үйлады. Күршесе бу эшне, хокукка ярашлы түгел дип санап, судка гариза тапшырды. Эшнең судта тикшерелүе өчен кайсы хокук нормалары нигез булып торыр?

**1)** экологик

**2)** административ

3) гуманитар

4) гражданлык

149. Саналып киткән хокук бозу күренешләре арасында кайсысы җинаять булып тора?

1) эшкә системалы рәвештә соңга калу

2) автобуста билетсыз бару

3) урамны тиешле булмаган җирдә аркылы чыгу

4) наркотиклар тарату

150. Түбәндәгеләрнең кайсысы хокук бозу күренеше булып тора?

1) дәүләт серен ачып салу

2) дуска биргән сүзне тотмау

3) борынгы тәнкәләрне җыю

4) башлыкның үзенең кул астындагы хезмәткәренә шелтә салу

151. Әхлактан аермалы буларак, хокук

1) иҗтимагый мөнәсәбәтләрне җайга сала

2) җәмәгать фикеренә таяна

3) дәүләт көче тарафыннан саклана

4) яхшылык һәм явызлык күзаллауларына таяна

152. Математикадан контроль эшкә әзерләнмичә, 11 нче сыйныфның ике укучысы аның үткәрелүен өзергә уйладылар. Алар, мәктәптә бомба салынган дип, полициягә шалтыраттылар. Укучыларның бу эшләре нәрсә булып тора?

1) административ хата эш
2) җинаять
3) дисциплинар бозу
4) гражданлык хата эше

153. Әхлак нормаларыннан аермалы буларак, хокук нормаларын үтәү нәрсә тарафыннан тәэмин ителә?

1) дәүләтнең мәҗбүр итү көче белән

2) җәмгыятьнең гадәтләре һәм традицияләре белән

3) юристлар фикере белән

4) җәмәгать фикере көче белән

154. РФ гражданының конституцион бурычларының берсе -

1) эшчәнлек төрен һәм профессия сайлау
2) дәүләт эше белән идарә итүдә катнашу
3) гадел хөкемдә катнашу
4) тарихи һәм мәдәни мирасны саклау

155. Халыкара гуманитар хокук нормалары кайчак кулланыла?

1) кораллы конфликтлар вакытында
2) дәүләтләр арасында икътисадый килешүнамәләр төзегәндә
3) әйләнә-тирәлекне саклаганда
4) табигый афәтләр вакытында

156. Ирле-хатынлы (парлар) никахларын өзәргә уйладылар. Бу мәсьәлә нинди шартта бары тик судта гына хәл ителергә мөмкин?

1) Парларның уртак балигъ булмаган балалары бар.
2) Парлар өч елдан артык бергә яшиләр.
3) Парлар бергә бизнес алып баралар.
4) Парлар никах килешүнамәсе төзегәннәр.

157. РФ Президенты сайлауларында гражданин А. сайлау участогына килде һәм кандидатларның берсе өчен тавыш бирде. Бу рәвешле гражданин үзенең кайсы хокукын тормышка ашыра?

1) мәдәни
2) гражданлык
3) социаль-икътисадый
4) сәяси

158. Саналып киткән нормаларның кайсы хезмәт хокукына карый?

1) Гражданин 18 яшендә эшкә сәләтле санала.
2) Монополизациягә һәм намуссыз көндәшлеккә юнәлтелгән икътисадый эшчәнлек рөхсәт ителми.

3) Эшкә ике айга кабул ителгәндә, хезмәткәрләргә сынау вакыты билгеләнми.

4) Үзбелдеклелек белән төзелеш алып барган затлар бу төзелешкә милек хокукы ала алмыйлар.

159. Гражданинның конституцион бурачы -

1) мәдәни тормышта катнашу

2) дәүләт эшләре белән идарә итүдә катнашу

3) табигатьне һәм әйләнә-тирәлекне саклау

4) ниндидер берләшмәгә керү

160. Гражданинның конституцион бурачы -

1) дәүләт органнарына мөрәҗәгать итү

2) сайлауларда катнашу

3) табигатьне һәм әйләнә-тирәлекне саклау

4) суд утырышларында хөкемче утырышчы сыйфатында катнашу

161. «Тикшерү эксперименты», «тентү» төшенчәләре кайсы төр эшчәнлеккә карый?

1) хакимиятнең закон чыгару органнарына

2) идарә итү органнарына

3) хокук саклау органнарына

4) суд хакимияте органнарына

162. Эшкә соңга калу кайсы хокук нормаларын боза?

1) административ

2) хезмәт

3) җинаять

4) гражданлык

163. Ата-ана берничә ел дәвамында үзләренең балаларына исем сайлый алмаганнар һәм аның тууын теркәмәгәннәр. Баланың нинди хокукы бозылган?

1) гаиләдә яшәү

2) исемгә һәм фамилиягә

3) үзенең ата-анасын белү

4) белемгә

164. Автобустан чыкканда, гражданка сумкасыннан акчалы янчык урланганын абайлый. Гражданкага, беренче чиратта, кая мөрәҗәгәть итәргә кирәк?

1) нотариаль конторага

2) судка

3) прокуратурага

4) полиция бүлегенә

165. Гражданнарга һәм оешмаларга профессиональ юридик консультация бирү кайда башкарыла?

1) прокуратурада

2) полициядә

3) адвокатурада

4) судта

166. 9«А» һәм 9«Б» сыйныфлары укучылары җәмгыять белеменә караган мәсьәлә чиштеләр: «14 яшьлек яшүсмерләр сатып җибәрү максаты белән мәктәпнең информатика кабинетыннан компьютер урладылар. Җинаять бик тиз ачыла: укучыларны мәктәптән чыгып барышлый тотып алалар. Укучылар җинаять җаваплылыгына тартылачакмы?»

Мәсьәләне үтәү нәтиҗәләре (сорауда катнашучылардан % -ларда) таблицада бирелгән.

| **Җавап варианты** | **% отвечавших** | |
|---|---|---|
| | 9 «А» | 9 «Б» |
| Әйе, тартылачак, чөнки 14 яше тулган затлар урлау өчен җинаять җаваплылыгына тартылырга тиеш. | 10 | 45 |
| Әйе, тартылачак, чөнки алар бер төркем затларның алдан сөйләшүе буенча җинаять кылалар. | 10 | 10 |
| Юк, чөнки җинаять җаваплылыгына җинаять кылган вакытка 16 яше тулган затлар гына җавапка тартыла. | 45 | 40 |

| | | |
|---|---|---|
| Юк, чөнки укучылар үзләренең планнарын ахырына кадәр башкара алмыйлар. | 5 | 5 |

Китерелгән исемлектән таблица нигезендә ясап булган нәтиҗәләрне табыгыз һәм алар астында бирелгән цифрларны язып куегыз.

| |
|---|
| 9«Б» укучылары яшүсмерләрнең бу эшләрен урлау дип классификациялэп, 9«А» укучыларына караганда, эшне яхшырак башкаралар. |
| Ике сыйныфның да бары унынчы укучысы гына үз җавабын дөрес итеп дәлилли алган. |
| Һәрбер сыйныфта да аз күләмдәге укучылары җаваплылыкны тәмамланган гамәл белән бәйли. |
| 9«Б» сыйныфы укучыларына караганда, җинаять җаваплылыгына җинаять кылган вакытка 16 яше тулган затларга карый дип билгеләп, 9«А» укучылары эшне яхшырак башкаралар. |

Һәбер сыйныфның яртыдан күбрәк укучысы дөрес җавап

167. Z һәм Y илләрендә җәмәгать фикерен өйрәнә торган фондларның берсе балигъ булганнар арасында “Хокук саклау органнарына ышанасызмы?” дигән темага сорау алу үткәрде.

Алынган нәтиҗәләр (сорау алучылардан в % -ларда) таблицада бирелгән.

| **Җавап варианты** | **% җавап бирүчеләр** | |
|---|---|---|
| | **Z иле** | **Y иле** |
| Ышанам, чөнки алар гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклыйлар | 25 | 10 |
| Ышанам, чөнки анда чын профессионаллар эшли | 30 | 15 |
| Шикләнеп карыйм, чөнки аларның хезмәткәрләре һәрвакытта да закон сакламыйлар. | 20 | 35 |
| Ышанмыйм | 15 | 35 |
| Җавап бирергә авырыксындылар | 10 | 5 |

Таблицада чагылыш тапкан мәгълүматлар , масскакүләм мәгълүматл чараларында басылып чыга һәм аңлатма бирелә.

Түбәндә китерелгән нәтиҗәләрнең кайсылары башкарылган эш нәтиҗәләреннән килеп чыга?

Алар астында күрсәтелгән цифрларны язып куегыз.

168. Китерелгән исемлектән таблица нигезендә ясап булган нәтиҗәләрне табыгыз һәм алар астында бирелгән цифрларны язып куегыз.

**1)** Z илендә яшәүчеләрдән сорау алуда катнашучылар арасында хокук

саклау органнарына ышанучылар саны аларга шикләнеп караучылар санынннан күбрәк.

2) Y иленең сорау алуда катнашучылар арасында хокук саклау органнарына ышанучыларның сумма өлеше аларга шикләнеп караучылар санынннан азрак.

3) Анда чын профессионаллар эшләгәнгә күрә, хокук саклау органнарына ышанучыларның саны, Z иленә караганда, Y илендә күбрәк.

4) Z илендә сорау алуда катнашканнарның дүрттән бер өлеше хокук саклау органнарына ышаналар, чөнки алар гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклыйлар.

5) Y иленең сорау алуда катнашканнарның тигез өлеше хокук саклау органнарына ышанмыйлар һәм аларга шикләнеп карыйлар.